**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш., **БОЕРЫК**

**03.02. 2014 ел** **N 70-П**

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару буенча дәүләт функциясен үтәү тәртибен раслау турында

«Атмосфера һавасын саклау турында» 1999 елның 4 маендагы 96-ФЗ номерлы федераль законны, «Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгару һәм аңа зарарлы физик йогынты ясау нормативлары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 2 мартындагы 183 номерлы карарын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карарын үтәү йөзеннән

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару буенча дәүләт функциясен үтәү тәртибен расларга;
2. Дәүләт экология экспертизасы һәм әйләнә-тирәлеккә йогынтыны нормага салу идарәсенә (Р.А.Шаһидуллина) югарыда күрсәтелгән Тәртип нигезендә эшләр башкаруны тәэмин итәргә;
3. Хокук бүлегенә (В.А.Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәүгә җибәрүне тәэмин итәргә;
4. Әлеге Боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрының беренче урынбасары Р.И.Камаловка йөкләргә.

Министр
А.Г.СИДОРОВ

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2014 елның 3 февралендәге
70-п номерлы боерыгына
кушымта

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару буенча дәүләт функциясен үтәү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару буенча дәүләт функциясен үтәү тәртибе (алга таба - Тәртип) атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба - Министрлык) гамәлләренең тәртибен, срокларын һәм эзлеклелеген (административ процедуралар) билгели.

2. Федераль дәүләт экология күзәтчелегенә карамаган объектлар өчен стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару буенча дәүләт функциясен үтәү түбәндәгеләр нигезендә башкарыла:

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон белән;

«Атмосфера һавасын саклау турында» 1999 елның 4 маендагы 96-ФЗ номерлы федераль закон белән;

«Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгару һәм аңа зарарлы физик йогынты ясау нормативлары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 елның 2 мартындагы  183 номерлы карары белән;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгарып ташлауларны һәм атмосфера һавасына зарарлы физик йогынтыларны чикләү, туктатып тору яки туктату тәртибе турында» 2002 елның 28 ноябрендәге 847 номерлы карары белән;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005елның 6 июлендәге   325 номерлы карары белән;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Атмосфера һавасына һәм аларның чыганакларына зарарлы йогынтыларны дәүләт исәбенә алу турындагы нигезләмәне

раслау хакында» 2000 елның 21 апрелендәге 373 номерлы карары белән.

3. Федераль дәүләт экология күзәтчелегенә карамаган индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга (алга таба - хуҗалык субъектлары) чыгаруга рөхсәтләр бирү тәртибе Министрлыкның 2012 елның 20 апрелендәге 143-п номерлы Боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламенты белән билгеләнә.

4. Чыгаруга рөхсәтләрне туктатып тору һәм юкка чыгару дәүләт экология күзәтчелеге (атмосфера һавасын саклауга күзәтчелек) буенча уздырылган чаралар нәтиҗәләре буенча башкарыла, аны үткәрү тәртибе, вакыты һәм сроклары түбәндәгеләр белән билгеләнгән:

- 2010 елның 23 мартындагы 212 номерлы Министрлык боерыгы белән расланган, Федераль дәүләт экология контроле узарга тиешле объектларда, шул исәптән пычраткыч матдәләрне һәм башка матдәләрне һавага чыгарган өчен түләүне дәүләт контроленнән тыш, атмосфера һавасын саклауга дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының административ регламенты;

- Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2012 елның 26 октябрендәге 424-п боерыгы белән расланган региональ дәүләти экологик күзәтчелекне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламенты (алга таба - Регламент ГЭН).

## II. Процедурлар

5. Стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару буенча дәүләт функциясен үтәү кысаларында түбәндәге процедуралар башкарыла:

- чыгару рөхсәтен туктату;
- чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару.

## III. Чыгаруга рөхсәтләрне туктату һәм гамәлдән чыгару буенча дәүләт функциясен үтәү тәртибенә таләпләр

6. Чыгару рөхсәтен туктату процедурасын үтәү шартлары һәм вакыты

6.1. Дәүләт экология күзәтчелеге Регламентында билгеләнгән, санап кителгән фактларның берсен ачыклау турында дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлык бүлекчәләреннән (Министрлыкның территориаль идарәләре, Дәүләт экология күзәтчелеге инспекциясе) мәгълүмат һәм башка документлаштырылган фактларны алу Министрлык тарафыннан чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору процедурасын башкару өчен нигез булып тора:

- үлчәүнең ялгышлыгын исәпкә алып, факттагы чыгарылышның норматив күрсәткечтән артып киткән булуы;

- атмосфера һавасын саклауга контроль булмау;

- начар метеорологик шартлар чорында чыгаруларны киметү планын үтәмәү;

- чыгаруга рөхсәт шартларын үтәмәү, шул исәптән атмосфера һавасына пычраткыч матдәләр чыгаруны киметү буенча расланган чаралар планын билгеләнгән срокларда үтәмәү яки тормышка ашырылган чараларның планлаштырылган нәтиҗәлелегенә ирешмәү.

6.2. Дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлык бүлекчәләреннән Министрлык чыгаруга рөхсәт бирүне туктатып тору өчен нигезләр ачыклау турында мәгълүмат һәм документлаштырылган башка фактлар алганда, Тәртипкә 1 нче кушымта рәвешендә, чыгаруга рөхсәтне туктатып тору өчен нигезләр ачыклау турында мәгълүмат алган көннән алып, 10 эш көненнән артмаган срокта, чыгаруга рөхсәт бирүне туктатып тору турында, чыгаруга рөхсәт хуҗасы булган хуҗалык итүче субъект адресына хат әзерли.

6.3. Чыгаруга рөхсәт хуҗасына Министрлык тарафыннан чыгаруга рөхсәтне туктатып тору турында, Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелгән, хат юллау чыгаруга рөхсәтне туктатып тору процедурасының ахыргы нәтиҗәсе булып тора.

6.4. Чыгаруга рөхсәт бирүнең гамәлдә булу вакытын туктатып тору турындагы мәгълүмат Министрлыкның бердәм бүленгән мәгълүмат-аналитика системасына (алга таба - ЕРИАС) кертелә, шулай ук Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә җибәрелә.

7. Чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару процедурасын үтәү шартлары һәм вакыты.

Чыгаруга рөхсәт чикле яисә вакытлыча килештерелгән чыгарулар күп тапкырлар арттырылган очракта юкка чыгарыла.

7.1. Рөхсәт ителә торган яисә вакытлыча килештерелгән чыгарып ташлауларның иң чик нормативларын гамәлгә яраксыз дип тану яисә рөхсәт ителә торган яисә вакытлыча килештерелгән ташлауларны берничә тапкыр арттыру турында дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлык бүлекчәләреннән мәгълүмат һәм документлаштырылган фактлар алу Министрлык тарафыннан чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару процедурасын үтәүне башлап җибәрү өчен нигез булып тора.

7.2. Иң чик мөмкин булган яисә вакытлыча килештерелгән чыгаруларны берничә тапкыр арттыру турында мәгълүмат һәм документлаштырылган фактларны алганда, Министрлык чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару өчен нигез булып торучы иң чик мөмкин яисә вакытлыча килештерелгән чыгаруларны нормативлары гамәлгә яраксыз дип танылган вакыттан алып ун эш көненнән артмаган срокта, рөхсәтне юкка чыгару турындагы чыгаруга рөхсәт хуҗасы булган хуҗалык итүче субъект адресына хат әзерли.

7.3. Чыгаруга рөхсәт хуҗасына Министрлык тарафыннан чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару турында, Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелгән, хат юллау чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару процедурасының ахыргы нәтиҗәсе булып тора.

7.4. Чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару турындагы мәгълүмат ЕРИАС кертелә, шулай ук Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә җибәрелә.

## IV. Чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булу вакытын туктатып тору һәм юкка чыгару буенча дәүләт функциясен үтәгәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

8. «Чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын туктатып тору» процедурасы

8.1. «Чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын туктатып тору» процедурасы түбәндәге гамәлләрне үз эченә ала:

- чыгаруга рөхсәтне туктатып тору өчен нигезләрне ачыклау һәм аларны теркәү турында мәгълүмат һәм башка документлаштырылган фактлар алу;
- җаваплы вазыйфаи затны билгеләп кую;
- чыгаруга рөхсәт бирүне туктатып тору өчен нигез булган дәүләт экология күзәтчелеге барышында ачыкланган мәгълүматны һәм башка документлаштырылган фактларны карау һәм тапшырылган мәгълүматның һәм чыгаруга рөхсәт бирүне туктатып тору өчен нигез булган документлар фактларының туры килүен бәяләү;
- хуҗалык итүче субъектка – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында хатны әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- хуҗалык итүче субъектка – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтне туктатып тору турында хат юллау;
- чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын туктату турында ЕРИАС мәгълүмат кертү

8.2. Чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору процедурасын башлау өчен нигезләр Тәртипнең 6.1 пунктында күрсәтелгән.

8.3. Дәүләт экология күзәтчелеге Регламенты билгеләгән Министрлыкның (Министрлыкның территориаль органнарының) вазыйфаи затлары, атмосфера һавасын саклауны күзәтү барышында чыгаруга рөхсәтне туктатып тору өчен нигезләр ачыкланганда, Министрлыкның әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру бүлегенә чыгаруга рөхсәтне туктатып тору өчен ачыкланган сәбәпләр турындагы мәгълүматны һәм башка документлаштырылган фактларны җибәрә.

Үтәү вакыты - хуҗалык субъектын тикшерү тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә.

8.4. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру бүлеге башлыгы (алга таба – бүлек башлыгы) билгеләнгән тәртиптә Министрлык документларының үтәлешен тикшереп тору бүлегендә теркәлгән мәгълүмат һәм әлеге Тәртипнең 6.1 пунктында күрсәтелгән фактлар нигезендә күрсәтелгән административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затны билгеләү турында карар кабул итә (алга таба – җаваплы башкаручы). Теркәлү һәм җаваплы башкаручыны билгеләү вакыты-күрсәтелгән мәгълүматлар һәм фактлар кергән көннән алып бер эш көненнән дә артмый.

8.5. Җаваплы башкаручы биш эш көненнән артмаган срокта чыгаруга рөхсәт бирүне туктатып тору һәм әлеге фактларның Тәртипнең 6.1 пунктында күрсәтелгән чыгаруга рөхсәт бирүне туктатып тору өчен нигезләмәләрнең туры килүен бәяләү өчен тәкъдим ителгән мәгълүматны һәм документлаштырылган фактларны карый.

Тәртипнең 6.1 пунктында күрсәтелгән чыгаруга рөхсәт бирүне туктатып тору өчен нигезләр булуы расланганда, җаваплы башкаручы хуҗалык итүче субъектка - чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында хатлар әзерли. Әзерләнгән хатларга билгеләнгән тәртиптә виза куела һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрелә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына имзага җибәрелгән хуҗалык итүче субъектка – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турындагы хатлар.

8.6. Бүлек башлыгы хуҗалык итүче субъектка - чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турындагы хатларны карый, дәүләт экология экспертизасы идарәсе башлыгына һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыруны килештерә һәм имзага җибәрә (алга таба – Идарә башлыгы).

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән, Идарә башлыгына имза салуга юнәлдерелгән хуҗалык итүче субъектка – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында хатлар.

8.7. Идарә башлыгы башлыгы хуҗалык итүче субъектка - чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турындагы хатларны карый, килештерә һәм министрның беренче урынбасарына имзага җибәрә.

Әлеге Тәртипнең 8.6-8.7 пунктчаларында билгеләнгән процедуралар алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килештерелгән Министрның беренче урынбасарына имза салуга юнәлдерелгән хуҗалык итүче субъектка - чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турындагы мәгълүмат белән хатлар.

8.8. Министрның беренче урынбасары хуҗалык итүче субъектка - чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турындагы хатларны имзалый һәм Министрлык документларының үтәлешен тикшереп тору бүлегенә җибәрә, аның хезмәткәре хатны терки һәм мәгълүматны керүче (чыгучы) документлар базасына кертә. Хат почта аша, чыгаруга рөхсәт бирүче хуҗалык итүче субъект адресына, шулай ук

дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә җибәрелә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: хуҗалык итүче субъектка – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында имзаланган, теркәлгән һәм җибәрелгән хатлар.

8.9. Чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын туктатып тору турында хатлар имзаланып, теркәү узып һәм хуҗалык итүче субъектка җибәрелгәннән соң, чыгаруга рөхсәтне туктатып тору турындагы мәгълүмат җаваплы башкаручы тарафыннан ЕРИАС кертелә.

8.10. Министрлыкның чыгаруга рөхсәтне туктатып тору процедурасын үтәү вакыты- чыгаруга рөхсәт бирүне туктатып тору өчен нигез булган, мәгълүмат һәм документлаштырылган фактларны алганнан соң ун эш көне.

8.11. Чыгаруга рөхсәтне туктатып тору процедурасының ахыргы нәтиҗәсе – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә, Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелгән, чыгаруга рөхсәтне туктатып тору турында Министрлык тарафыннан җибәрелгән хатлар.

9. «Чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын юкка чыгару» процедурасы

9.1. «Чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын юкка чыгару » процедурасы түбәндәге гамәлләрне үз эченә ала:

- чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару өчен нигезләрне ачыклау һәм аларны теркәү турында мәгълүмат һәм башка документлаштырылган фактлар алу;

җаваплы вазыйфаи затны билгеләп кую;

- чыгаруга рөхсәт бирүне юкка чыгару өчен нигез булган дәүләт экология күзәтчелеге барышында ачыкланган мәгълүматны һәм башка документлаштырылган фактларны карау һәм тапшырылган мәгълүматның һәм чыгаруга рөхсәт бирүне юкка чыгару өчен нигез булган документлар фактларының туры килүен бәяләү;

- хуҗалык итүче субъектка – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын юкка чыгару турында хатны әзерләү һәм рәсмиләштерү;

- хуҗалык итүче субъектка – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтне туктатып тору турында хат юллау;

Чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару турында ЕРИАС мәгълүмат кертү.

9.2. Чыгаруга рөхсәтне гамәлдән чыгару процедурасын башлау өчен нигезләр әлеге Тәртипнең 7.1 пунктында күрсәтелгән.

9.3. Дәүләт экология күзәтчелеге регламенты билгеләгән Министрлыкның (Министрлыкның территориаль органнарының) вазыйфаи затлары, атмосфера һавасын саклауны күзәтү барышында чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару өчен

нигезләр ачыкланганда, Министрлыкның әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру бүлегенә чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару өчен ачыкланган сәбәпләр турындагы мәгълүматны һәм башка документлаштырылган фактларны җибәрә.

Үтәү срогы – хуҗалык итүче субъектны тикшерү тәмамланган көннән алып бер эш көне эчендә.

9.4. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыру бүлеге башлыгы (алга таба – Бүлек башлыгы) билгеләнгән тәртиптә Министрлык документларының үтәлешен тикшереп тору бүлегендә теркәлгән мәгълүмат һәм әлеге Тәртипнең 7.1 пунктында күрсәтелгән фактлар нигезендә күрсәтелгән административ процедураны үтәү өчен җаваплы вазыйфаи затны билгеләү турында карар кабул итә (алга таба – җаваплы башкаручы). Теркәлү һәм җаваплы башкаручыны билгеләү вакыты – күрсәтелгән мәгълүматлар һәм фактлар кергән көннән алып бер эш көненнән дә артмый.

9.5. Җаваплы башкаручы биш эш көненнән артмаган срокта чыгаруга рөхсәт бирүне юкка чыгару һәм әлеге фактларның Тәртипнең 7.1 пунктында күрсәтелгән чыгаруга рөхсәт бирүне туктатып тору өчен нигезләмәләрнең туры килүен бәяләү өчен тәкъдим ителгән мәгълүматны һәм документлаштырылган фактларны карый.

Тәртипнең 7.1 пунктында күрсәтелгән чыгаруга рөхсәт бирүне юкка чыгару өчен нигезләр булуы расланганда, җаваплы башкаручы хуҗалык итүче субъектка – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын юкка чыгару турында хатлар әзерли. Әзерләнгән хатларга билгеләнгән тәртиптә виза куела һәм килештерү өчен Бүлек башлыгына җибәрелә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына имзага җибәрелгән хуҗалык итүче субъектка – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын юкка чыгару турындагы хатлар.

9.6. Бүлек башлыгы хуҗалык итүче субъектка - чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын юкка чыгару турындагы хатларны карый, дәүләт экология экспертизасы идарәсе башлыгына һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны нормалаштыруны килештерә һәм имзага җибәрә (алга таба – Идарә башлыгы).

Процедуралар нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән, Идарә башлыгына имза салуга юнәлдерелгән хуҗалык итүче субъектка – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын юкка чыгару турында хатлар.

9.7. Идарә башлыгы башлыгы хуҗалык итүче субъектка – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын юкка чыгару турындагы хатларны карый, килештерә һәм министрның беренче урынбасарына имзага җибәрә.

Әлеге Тәртипнең 9.6-9.7 пунктчаларында билгеләнгән процедуралар алдагы

процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә башкарыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килештерелгән Министрның беренче урынбасарына имза салуга юнәлдерелгән хуҗалык итүче субъектка - чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын юкка чыгару турындагы мәгълүмат белән хатлар.

9.8. Министрның беренче урынбасары хуҗалык итүче субъектка - чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын юкка чыгару турындагы хатларны имзалый һәм Министрлык документларының үтәлешен тикшереп тору бүлегенә җибәрә, аның хезмәткәре хатны терки һәм мәгълүматны керүче (чыгучы) документлар базасына кертә. Хат почта аша, чыгаруга рөхсәт бирүче хуҗалык итүче субъект адресына, шулай ук дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә җибәрелә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: хуҗалык итүче субъектка - чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын юка чыгару турында имзаланган, теркәлгән һәм җибәрелгән хатлар.

9.9. Чыгаруга рөхсәтнең гамәлдә булуын юкка чыгару турында хатлар имзаланып, теркәү узып һәм хуҗалык итүче субъектка җибәрелгәннән соң, чыгаруга рөхсәтне туктатып тору турындагы мәгълүмат җаваплы башкаручы тарафыннан ЕРИАС кертелә.

9.10. Министрлыкның чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару процедурасын үтәү вакыты- чыгаруга рөхсәт бирүне юкка чыгару өчен нигез булган, мәгълүмат һәм документлаштырылган фактларны алганнан соң ун эш көне.

9.11. Чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару процедурасының ахыргы нәтиҗәсе – чыгаруга рөхсәт хуҗасына һәм дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы Министрлыкның тиешле территориаль идарәсенә, Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә рәсмиләштерелгән, чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару турында Министрлык тарафыннан җибәрелгән хатлар.

10. Министрлыкның чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору яки юкка чыгару буенча турындагы карарларына суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать<br>ресурслары министрлыгының стационар

чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы
(пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең
гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару
буенча дәүләт функциясен үтәү тәртибенә
1 нче кушымта

Рәвеше

Стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору турында хат

Хуҗалык итүче субъект исеме
Почта адресы

Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч)
матдәләр чыгаруга рөхсәтне туктатып тору
турында

Түбәндә санап үтелгән нигезләр буенча "__" ___________ 20__ ел. N _____ стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору турында карар кабул ителү турында хәбәр итәм:
__________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________
(чыгаруга рөхсәтне туктатып тору өчен нигезләрне күрсәтергә)

Министрның беренче урынбасары яисә аны алмаштыручы затның имзасы _____________________ фамилиясе, инициаллары

Җаваплы башкаручы ФИА
телефон номеры

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының стационар

чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы
(пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең
гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару
буенча дәүләт функциясен үтәү тәртибенә
2 нче кушымта

Рәвеше

Стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын юкка чыгару турында хат

Хуҗалык итүче субъект исеме

Почта адресы

Атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч)
матдәләр чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару
турында

Түбәндә санап үтелгән нигезләр буенча "__" ___________ 20__ ел. N _____ стационар чыганаклардан атмосфера һавасына зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын юкка чыгару турында карар кабул ителү турында хәбәр итәм:

______________________________________________________________________

(чыгаруга рөхсәтне юкка чыгару өчен нигезләрне күрсәтергә)

______________________________________________________________________

Министрның беренче урынбасары яисә аны алмаштыручы затның имзасы _____________________ Фамилиясе, инициаллары

Җаваплы башкаручы ФИА
телефон номеры